РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
ТОЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ТУЙКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ул.Джалиля , д.19, с.Түйкә,
Азнакаевский район, 423302

Җәлил ур., 19 нче йорт, Туйкә авылы,
Азнакай районы, 423302

Тел./факс(885592)-45089; E-mail: Toy.Azn@tatar.ru,

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01 ноябрь 2025ел

№4

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Түйкә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Туйкә авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар итәм:

1. 2025 елның 14 ноябрендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Туйкә авыл җирлегенең Туйкә торак пунктында Туйкә авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2 Билгеләү:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Туйкә авыл җирлегенең Туйкә торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Туйкә авыл җирлеге башкарма комитеты;

– гражданнар җыенын үткәрү вакыты-2025 елның 14 ноябрендә 10.00 сәгатьтән 11.30 сәгатькә кадәр;

– гражданнар җыенын уздыру урыны-Туйкә авылы, Гагарин ур., 4А йорт, Туйкә авылы мәдәният йорты залы;

3.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

-2025елның 01 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Түйкә авылы, Җәлил урамы,19 йорт;

- сайлау хокукына ия булган Түйкә торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Түйкә торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез, 2026елда Түйкә авыл җирлеге Түйкә торак пункты территориясендә 1,2 төркем

инвалидлардан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар, аларның гаиләә әгъзалары, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнар дан  тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә,  80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр өчен 200 сум  күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп  үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган  түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (юлларны һәм территорияләрне кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, чапкыч сатып алу, үлән чабу, чүп җыю, агач һәм куакларны кисү);
- ремонт, киртәләр кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү (үлән чабу, чүп-чар җыю, зиратта агач һәм куакларны кисү, гербицид сатып алу, тоташ гербицид белән химик эшкәртү ) ;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Гагарин, Яшьләр урамнары буенча вак таш сатып алу, төяү, ташу, салу, Яшьләр урамындагы юлны профильләштерү)

« РИЗА»   «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.  һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, һәм түбәндәге адреслар җуенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы, Җәлили ур.,19 йорт;
ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы Гагарин ур., 4а йорт;
ТР, Азнакай муниципаль районы, Камышлы-Күл, Ленин ур., тукталыш янында;
ТР, Азнакай муниципаль районы,  Карамалы-Елга ур., Сәйдәшев ур., № 19а йорт янында;

7. Әлеге карар  игълан ителгән көннән үз көченә керә.
8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Рәис   Р.Р.Закирова